| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**СОВЕТ**<br>**Старосляковского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Иске Эсләк авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

06.12.2023 Иске Эсләк авылы № 42-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге Советының "Җир салымы турында" 21.11.2017 елның 32-2 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 394 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге Советының "Җир салымы турында" 20.11.2017 елның 32-2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 9 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-Башка җир кишәрлекләренә карата 1,5 %.».

2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Җир салымы турында» 21.11.2017 елның 32-2 номерлы Иске Эсләк авыл җирлеге Советы карарына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге Советының 12.10.2023 елның 39-2 номерлы карарының 1 пунктындагы 1.1 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлегенең мәгълүмат стендында урнаштырырга, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Д.М.Әхмәтов

Совет Старосляковского сельского поселения
Иске Эсләк авыл җирлеге Советы
АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИНН 1601002580